# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Лениногорск муниципаль районы составына керүче "Иске Шөгер авыл җирлеге" һәм "Шөгер авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

Лениногорск муниципаль районы составына керүче "Яңа Чыршылы авыл җирлеге" һәм "Писмән авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен "Писмән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең "Яңа Чыршылы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә урнашкан басу аша кишәрлеген "Яңа Чыршылы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү юлы белән үзгәртергә.

**3 статья**

"Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 34-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) ундүртенче абзацта "Вәлиев поселогы" сүзләрен "Александровка, Вәлиев поселоклары" сүзләренә алмаштырырга;

б) унбишенче абзацта "Александровка," сүзен төшереп калдырырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

# "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- -муниципаль район чиге
- 25 -тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 -җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- -торак пунктлар
- -муниципаль районның административ үзәге
- -җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *20 (26) - 1 (77)* | - Чирмешән муниципаль районы |
| *1(77) - 35 (76)* | - Әлмәт муниципаль районы |
| *35 (76) - 51 (25)* | - Бөгелмә муниципаль районы |
| *51(25) - 20 (36)* | - Самара өлкәсе |

"Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Лениногорск шәһәре |
| 2 | Глазово авыл җирлеге |
| 3 | Зәй-Каратай авыл җирлеге |
| 4 | Зеленая Роща авыл җирлеге |
| 5 | Ивановка авыл җирлеге |
| 6 | Керкәле авыл җирлеге |
| 7 | Кармалка авыл җирлеге |
| 8 | Кирлегәч авыл җирлеге |
| 9 | Куакбаш авыл җирлеге |
| 10 | Мичурин авыл җирлеге |
| 11 | Мөэмин-Каратай авыл җирлеге |
| 12 | Түбән Чыршылы авыл җирлеге |
| 13 | Яңа Иштирәк авыл җирлеге |
| 14 | Яңа Чыршылы авыл җирлеге |
| 15 | Писмән авыл җирлеге |
| 16 | Сарабиккол авыл җирлеге |
| 17 | Иске Иштирәк авыл җирлеге |
| 18 | Иске Куак авыл җирлеге |
| 19 | Иске Шөгер авыл җирлеге |
| 20 | Сугышлы авыл җирлеге |
| 21 | Тимәш авыл җирлеге |
| 22 | Туктар Урдаласы авыл җирлеге |
| 23 | Ормышлы авыл җирлеге |
| 24 | Аланлык авыл җирлеге |
| 25 | Шөгер авыл җирлеге"; |

3) 8 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Туктар Урдаласы" сүзләреннән соң "һәм Шөгер" сүзләрен өстәргә;

б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Керкәле авыл җирлеге чиге Иске Шөгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км урман

полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 70 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 270 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 90 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 190 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба, 28 м төньяк-көнчыгышка таба Керкәле, Иске Шөгер һәм Шөгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керкәле авылыннан 1,38 км көньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр, шулай ук Керкәле, Иске Шөгер һәм Шөгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керкәле авылыннан 1,37 км көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба, Урман Чишмәсе елгасын кисеп үтеп, 200 м көнчыгышка таба, 540 м төньяк-көнчыгышка таба, автомобиль юлын кисеп үтеп, 330 м төньяк-көнбатышка таба, 220 м төньяк-көнчыгышка таба "Лениногорск урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шөгер участок урманчылыгындагы 61 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, шуннан соң әлеге урманчылыктагы 61, 58, 59, 53, 48, 44, 37, 35, 33 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кузайка елгасы башына кадәр, шуннан соң шул ук юнәлештә шушы елга буенча 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Керкәле авыл җирлеге чиге Шөгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып, Шөгер – Керкәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 27 м көньяк-көнбатышка таба 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

4) 16 нчы кушымтадагы җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 17 нче кушымтадагы унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 21 нче кушымтада:

а) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Иске Шөгер авыл җирлеге чиге Керкәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 70 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 270 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 90 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 190 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба, 28 м төньяк-көнчыгышка таба Керкәле, Иске Шөгер һәм Шөгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керкәле авылыннан 1,38 км көньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр, шулай ук Керкәле, Иске Шөгер һәм Шөгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керкәле

авылыннан 1,37 км көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба, Урман Чишмәсе елгасын кисеп үтеп, 200 м көнчыгышка таба, 540 м төньяк-көнчыгышка таба, автомобиль юлын кисеп үтеп, 330 м төньяк-көнбатышка таба, 220 м төньяк-көнчыгышка таба "Лениногорск урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шөгер участок урманчылыгындагы 61 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагына кадәр бара, шуннан соң шушы урманчылыктагы 61, 58, 59, 53, 48, 44, 37, 35, 33 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кузайка елгасы башына кадәр, шуннан соң шул ук юнәлештә шушы елга буенча 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

б) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Иске Шөгер авыл җирлеге чиге Шөгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып 325 м төньяк-көнбатышка таба Шөгер – Керкәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньягы буйлап уза, шуннан соң Шөгер авылын көньяк кырыеннан әйләнеп уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 1,2 км Урман Чишмәсе елгасына кадәр бара, шушы елга буенча көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 120 м текә ярга кадәр, аннары текә ярның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба Шөгер авылының төньяк почмагына кадәр, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км Куакбаш – Керкәле автомобиль юлы буйлап, аннары көньяк-көнбатышка таба 500 м Урман Чишмәсе елгасына кадәр уза, 1,2 км шушы елга агымы буенча аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 22 м, аннары көньяк-көнчыгышка таба Шөгер – Керкәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньягы буйлап 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

7) 27 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шөгер авыл җирлеге Керкәле һәм Иске Шөгер авыл җирлекләре белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Шөгер авыл җирлеге чиге Иске Шөгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Керкәле, Иске Шөгер һәм Шөгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керкәле авылыннан 1,38 км көньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып 325 м төньяк-көнбатышка таба Шөгер – Керкәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньягы буйлап уза, шуннан соң Шөгер авылын көньяк кырыеннан әйләнеп уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба борыла һәм 1,2 км Урман Чишмәсе елгасына кадәр бара, шушы елга буенча көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 120 м текә ярга кадәр, аннары текә ярның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба Шөгер авылының төньяк почмагына кадәр, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км Куакбаш – Керкәле автомобиль юлы буйлап, аннары

көньяк-көнбатышка таба 500 м Урман Чишмәсе елгасына кадәр уза, 1,2 км шушы елга агымы буенча аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 22 м, аннары көньяк-көнчыгышка таба Шөгер – Керкәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньягы буйлап Керкәле, Иске Шөгер һәм Шөгер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керкәле авылыннан 1,37 км көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Шөгер авыл җирлеге чиге Керкәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып, Шөгер – Керкәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 27 м көньяк-көнбатышка таба 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.".

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 25-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

## Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» һәм «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чиктәш чиге участогы карта-схемасы




Шартлы билгеләр

жирлекләрнең чикләре

Шөгер авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Иске Шөгер авыл җирлеге территориясе

торак пункт